**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**
**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге составына керүче Олы Ачасыры авылы торак пунктында**

**2019 елның 8 декабре** **№1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Олы Ачасыр авыл җирлеге составына керүче Олы Ачасыры авылында гражданнар җыены **Карар итте:**

1. 2020 елда Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге составына керүче Олы Ачасыр авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан тыш, һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

2.1 Җирлек чикләрендә автомобиль юлларын ремонтлау һәм карап тоту, инерт материаллар сатып алу, шул исәптән объектларны техник паспортлаштыру;

2.2 Ирекле янгын сүндерү сагы һәм махсуслаштырылган техниканы тоту, шул исәптән ягулык-майлау материаллары сатып алу;

2.3 Контейнер мәйданчыклары төзү;

2.4 Смета документациясен әзерләү, төзелеш контролен тормышка ашыру.

3. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук мәгълүмат стендларында: Олы Ачасыр авылы, Үзәк урамы, 46 йорт (җирлек хакимияте бинасы), Олы Ачасыр авылы, Кооператив урамы, 26 йорт (авыл мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче,**
**Олы Ачасыр авыл жирлеге башлыгы** **М.Г. Гатиятуллин**